| | |
|---|---|
| ГЛАВА<br>ЗВЕЗДИНСКОГО СЕЛЬСКОГО<br>ПОСЕЛЕНИЯ ДРОЖЖАНОВСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>ЧҮПРӘЛЕ<br>МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ<br>ЗВЕЗДА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ<br>БАШЛЫГЫ |

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

Хорновар-Шигали авылы

2021 елның 18 ноябре № 16

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлегенең Урманасты Шигали торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Уставының 12.1 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлеге Советының 11.10.2019 ел, №53/1 карары (2019елның 15 ноябрендәге 55/6 редакөиясендә) белән расланган Татарстан Республикасы Чупрәле муниөипалҗ районы Звезда авыл җирлеге торак пунктларында гранданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турындагы нигезләмәсе нигезендә КАРАР ИТӘМ:

1. Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районы Звезда авыл җирлегенең Урманасты Шигали торак пунктында 2021 елның 2 декабрenә 13:30 сәгатьтә Татарстан Республикасы, Чүпрәле районы, Хоновар-Шигали авылы, Центральная урамы, 5а нче йорт, Хорновар-Шигали авыл мәдәният йорты адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә

2. Халык җыенына чыгарыла торган түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының Звезда авыл җирлеге Урманасты Шигали торак пункыты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булмаган һәр кешедән 2022 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?

- Урманасты Шигали авылында карт агачларны кисү;
- Урманасты Шигали авылында урам утларын ремонтлау

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Әлеге карар рәсми бастырып чыгарылырга (халыкка җиткерелергә) тиеш.

Звезда авыл җирлеге башлыгы: М.В.Денисова